КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 сентябрь г.Казань № 883

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәткәндә клиникада файдалану өчен медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 август, 590 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәткәндә клиникада файдалану өчен медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 август, 590 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыру кысаларында медицина ярдәме

күрсәткәндә клиникада файдалану өчен медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибендә:

исемендә «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның дүртенче абзацында «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Донор канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортлау һәм клиникада файдалану кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 елның 22 июнендәге 797 номерлы карары белән расланган Донор канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортлау һәм клиникада файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.»;

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Донор каны һәм (яисә) аның компонентлары, донор канын һәм (яки) аның компонентларын клиникада файдалану белән бәйле медицина документларының, шул исәптән электрон документлар формасындагы документларның унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 1157н номерлы боерыгы белән расланган 421/1у формасы буенча һәм билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән клиникада файдалану өчен донор канына һәм аның компонентларына җыелма заявка;»;

11 пунктта «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин